*Дәхи Мөхәммәд галәйһис-сәламгә җитмеш мәртәбә салават әйтер. Дәхи дә Гашура көнне кардәшләре белән күрешер, Коръән мәҗлесендә ислам галимнәре белән очрашып сөхбәт, ягъни сөйләшеп фикер алышыр, ятимнәргә садака өләшеп бик зур савапларга ирешер»,* – дигән.

Гашура көнне тәмле-тәмле ризыклар әзерләп, гаилә белән бергә-бергә утыру хәерле. Коръән укып, изге теләкләр теләсәк, Сөбханә вә Тәгалә бу гаиләнең ризыгын ел буе киң итәр, дигән сүз дә бар. Шуңа күрә бу көнне ачык йөз белән бәйрәм итеп, Хак Тәгаләдән хәерле гомер, киң ризыклар сорап, матур итеп билгеләп үтик. Без инде шушы аерым көннәрдә генә түгел, ел буе да шулай тәртипле, иманлы булырга тиешбез.

Газиз кардәшләрем! Гашура көнендә Хак Сөбханә вә Тәгалә тел ачкычлары биреп, мәчетләрдә вә мәҗлесләргә чакырылган булсагыз, бик күп дини китаплардан файдаланып, мин язган мәкаләләргә таянып, хәерле вәгазьләр сөйләргә һәркайсыгызга насыйп кылса иде.

Гашура көнне изге гамәлләрне күбрәк кылып, Җәнаббел-Хак кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәүләрне барчабызга да насыйп әйләсә иде. Гашура бәйрәмендә вә яңа елның беренче аенда – мөхәррәм аенда Газзә вә Җәлләдән үзебез өчен, балаларыбыз өчен, туганнарыбыз өчен, туган ватаныбыз өчен, газиз милләтебез өчен киләчәктә дә изгелекләр сорыйк, күп итеп догалар кылыйк, иншаллаһ, Хак Тәгалә безне ишетер вә аларның бөтенесен дә кабул итәр.

Гашура бәйрәме мөбарәк булсын! Әмин, Раббил галәмин, бирахмәтикә йә әрхамәррахимин!

Үәссәламугаләйкүм үә рахмәтуллаһи үә бәракәтүһ!

*("Дин вә йола" газетасыннан)*

# Гашура көне фазыйләтләре

Гашура бәйрәме көнне Пәйгамбәребез галәйһис-сәлам һәм аның сәхабәләре, бу көнне хөрмәтләп, ураза тотканнар. Гашура көненең нинди фазыйләтләре бар?

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим. Бу көннең фазыйләтләре вә хикмәтләре бихисаптыр.

Гашура көнне Пәйгамбәребез галәйһис-сәламнең яраткан оныгы хәзрәти Хөсәен ибне Әбү Талиб, гөнаһкяр, залимнәр кулыннан вәхшиләрчә һәлак ителә. Аның белән бергә берничә дистә башка каһарманнар да шәһит китә. Гашура хикмәтле көн булып кала бирә. Ягъни котылу һәм арыну, дөньяга килү һәм шәһитләрнең дөньядан китүе – барысы да бер Гашура көнне була.

Пәйгамбәребез галәйһис-сәлам: *«Пәйгамбәрегез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм дә Гашура көнне туган. Кыямәт көне дә Гашура көнне булачак»,* – дигән.

Риваять кылына: Гашура көне иде, бер фәкыйрь кеше бик бай булучы мөселман кардәшенә бара һәм, гозерләнеп, аңа мөрәҗәгать итә: «Мин – бер фәкыйрь адәм. Күп кенә балаларым бар. Бу мөбарәк көнне көтеп алып, сиңа килеп ярдәм сорарга булдым. Миңа 2 батман икмәк, 10 батман ит һәм 2 көмеш акча бирмәссең микән? Бу мөбарәк көнне балаларым туйганчы ашарлар иде! Аллаһы Тәгалә исә сиңа моны артыгы белән кайтарыр иде!» Бай аны тыңлап бетергәч, өйлә вакытына килергә куша, ягъни хәзер мондый вак эшләр белән шөгыльләнергә вакытым юк, өйлә җиткәч, сораганыңны бирермен дип, фәкыйрьне ышандыра. Өйлә вакыты җитә, бай фәкыйрьгә бернәрсә дә бирми, әмма аны икенде вакытында, икенде вакыты җиткәч, ахшам вакытына чакыра. Ахшам җиткәч, бай фәкыйрьгә: «Минем сиңа бирерлек бернәрсәм юк һәм бирәчәгем дә юк!» – дип фәкыйрьне рәнҗетеп җибәрә. Фәкыйрь бик каты хәсрәтләнеп, күзләренә яшьләр тулган килеш, өенә юл тота. Юлда моңа бер нәсара (христиан) очрый. Нәсара: «Әй фәлән, ни өчен елыйсың? Нәрсә булды?» – дип аннан сорый. Фәкыйрь исә: «Син һичбер нәрсә турында да миннән сорама!» – дип кенә әйтә. Әмма нәсара кабат фәкыйрьдән аны борчыган нәрсә хакында сорый. Өченче мәртәбә ул: "Ходай өчен дип әйтәм, әйт, нәрсә булды? Ни өчен елыйсың?» – дип сорагач, фәкыйрь нәсарага нәрсә булганын сөйләп бирә. Шуннан соң нәсара: «Бүген сезнең бер бәйрәм ләбаса, шулай түгелме соң?» – дип фәкыйрьдән сорый. Фәкыйрь: «Әйе, бүген безнең Гашура бәйрәме көне!» – ди. Нәсараның күңеле йомшара, һәм ул мөселман фәкыйрьгә ипи, ит, акчадан ике көмеш урынына егермене бирә. «Мин Аллаһы Тәгаләнең бүгенге бәйрәм көне хакына үзеңә ай саен шулай ярдәм итәргә вәгъдә бирәмен», – ди. Фәкыйрь шатлана-шатлана балалары янына кайта. Балалары исә: «И сөекле вә рәхимле Раббыбыз! Без, фәкыйрьләрне, шатландырып, күңелләребезгә шатлык кертүченең үзен шатландырсаң иде!» – дип дога кылалар...

Кич җитә. Бай йокыга китә. Төшендә ул алтын-көмештән ике сарай күрә. Бай: «И Раббым! Бу сарайлар кемгә була?» – дип, сарайларның матурлыгына гаҗәпләнә. «Әгәр фәкыйрь үзеңнән сораганны биргән булсаң, бу сарайлар сиңа булган булыр иде! Аның гозерен үтәмәгән сәбәпле, сарайлар аңа ярдәм иткән нәсарага булачак!» – дию белән бай уянып китә. Төшенә аптырап, ул фәкыйрьгә ярдәм иткән нәсараны эзләргә керешә. Нәсараны табып, аннан кемгә, ничек ярдәм итүен төпченә. Шуннан нәсара үзе бу байның ни өчен шулай кызыксынганын ачыкларга була. Бай аңа нәрсә булганын сөйли һәм шуннан соң: «Син миңа бу фәкыйрьгә ярдәм итү вәгъдәсен 100 мең көмешкә сатып бирсәң иде», – ди. Нәсара исә: «Мин бу сүземне җир йөзендә булган бөтен алтын хәзинәсенә дә алмаштырмаячакмын. Шәһит бул! Мин





**УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ИҖАТЫ**

# Динебезне хөрмәт итик!

*Иртә торып йортка чыксам,*
*Күтәрелә томаннар.*
*Фани дөнья вакытлыча,*
*Бер китәрбез, туганнар.*

*Кара гүргә барып кергәч,*
*Сөаль бирәсебез бар.*
*Дөньябыз иркен булса да,*
*Ләхетебез булыр тар.*

*Сөаль фәрештәсе килгәч,*
*Ни җаваплар бирербез?*
*Сораулары каты булыр,*
*Ничек итеп түзәрбез?!*

*Бакый дөнья мәңгелек ул,*
*Бик тә нык әзерләник.*
*Ходаебыз һәм Пәйгамбәрнең*
*Өммәтләреннән булыйк.*

*Кеше гөнаһсыз була алмый,*
*Илаһ шулай яралткан.*
*Байлык куып, динне онытып,*
*Ялгышмаска Ул кушкан.*

*Ислам дине — иң дөрес дин,*
*Аны бик нык хөрмәтлик!*
*Илаһымнан гафу сорап,*
*Һәр көн теләкләр телик.*

**Халидә ШӘКҮРОВА.**
Камышлы авылы.

# Изгелек кылыйк!

*Табигатебез шулай яратылган,*
*Аккан сулар кире акмыйлар.*
*Яшьлек елларының җимешләрен*
*Гомер уткән саен татыйлар.*

*Бар тереклек мәңгелеккә килми,*
*Аллаһы Тәгалә шулай яралткан.*
*Берсен шатлык, икенчесен сагыш көтә,*
*Кемдер өчен соңгы таң аткан.*

*Бер "рәхмәт" сүзе күпме савапка ия,*
*Игътибарны читкә юнәлтмик.*
*Күңел җылыбызны кызганмыйча,*
*Бер-беребезгә хөрмәт күрсәтик!*

*Яшәешнең ямен-тәмен тоеп,*
*Җирдә калдырыйк якты истәлек.*
*Игелекләребез үзебезгә кайтыр*
*Гомер буебызга җитәрлек.*

**Саимә МОРЗАХАНОВА.**
Гали авылы,
Похвистнево районы.

**МӨНӘҖӘТ**

# Зикер

*Әй, Ходаем, Раббым Аллам,*
*Җан биргәнгә шөкер кылам.*
*Мәңге Сиңа табынучы*
*Бер фәкыйрең, колың булам.*

*Әй, Ходаем, шөкер кылам*
*Яратканга адәм итеп.*
*Шул санаулы гомеркәем*
*Китмәсенче әрәм үтеп.*

*Әй, Ходаем, Раббым Аллам,*
*Бирче тәүфыйк, миһербанлык.*
*Җан сафлыгы, тән пакьлеге,*
*Шулдыр димен мөселманлык.*

*Әй, Ходаем, ярлыкый күр*
*Абайламый гөнаһ кылсам.*
*Белмәенчә, сизмәенчә*
*Гөнаһлыга юлдаш булсам.*

*Әй, Ходаем, фанилыктан*
*Үтсәм иде тыйнак кына.*
*Бу дөньяда без, адәмнәр,*
*Килеп-киткән кунак кына.*

*Әй, Ходаем, мин карыймын*
*Бер уңыма, бер сулыма.*
*Адашмаска, ялгышмаска*
*Коръән алдым мин кулыма.*

*Әй, Ходаем, борчыламын:*
*Күпме икән савапларым?*
*Гүр ишеген ачып кергәч,*
*Ничек булыр җавапларым?*

*Әй, Ходаем, кодрәтең киң,*
*Барчабызга рәхмәтең бер.*
*Хак мөселман юлын тотсам,*
*Ике дөнья рәхәтен бир.*

*Әй, Ходаем, көн итәргә*
*Бирче куәт, булыйм түзем.*
*Бакыйлыкка киткән чакта*
*"Аллаһ" булсын соңгы сүзем.*

*Әй, Ходаем, Раббым Аллам,*
*Теләк әйттем, зикер әйттем.*
*Әлхәмдулилләһи диеп,*
*Биргәненә шөкер иттем.*
*Амин.*

**Динә ГАЛИУЛЛОВА.**
Тольятти шәһәре.